Гыйлаҗев Т.Ш.

Казан

# И.Нуруллинның Г.Тукай иҗатын бәяләү һәм чорларга бүлү принциплары

И.Нуруллинның күпкырлы һәм киң диапазонлы гыйльми эшчәнлегендә Г.Тукай иҗаты төп урынны алып тора. Ул үзенең бөтен гомерен Г.Тукайга багышлап, бу өлкәдә бертуктаусыз яратып һәм актив эшли. XX гасырда Тукай гыйльмиятен үстерүгә, аның офыкларын киңәйтүгә үзеннән зур өлеш кертеп, чын мәгънәсендә тукайчы галим буларак танылa.

И.Нуруллин фәнни-гыйльми эшчәнлек белән әдәбият белеменең вульгар социологизм шаукымыннан арынуга йөз тоткан елларында шөгыльләнә башлый. Мәгълүм булганча, марксистик-ленинчыл фәлсәфә һәм эстетика кысаларына кертеп утыртылган әдәбият теориясе һәм тәнкыйть, матур әдәбиятны тикшерүдә эстетик һәм психологик аспектларны икенче планга калдырып, социологик принципка өстенлек бирә.

Әдәби әсәр эчтәлеге категорияләреннән сыйнфыйлык һәм идеялелек матур әдәбиятны бәяләүнең төп бизмәне буларак кабул ителгән шартларда И.Нуруллин «Тукай эстетикасы» (1956) (1) дигән тәүге хезмәтендә үз игътибарын, иң беренче нәүбәттә, шагыйрьнең иҗтимагый-сәяси карашларын ачыклауга юнәлтә һәм аның формалашуын Россиядәге иҗтимагый-сәяси вәзгыять, ил эчендәге һәм дөньякүләм тарихи вакыйгалар һәм марксизм өйрәтүләре белән тыгыз бәйләнештә карый.

Мәгърифәтче Г.Тукайның башлангыч чорында иҗат һәм сәяси фикер активлыгы шагыйрьнең мәгърифәткә булган ышанычын какшатып, Тукайның дөньяга карашларында инкыйлаби-демократик идеяләргә борылыш ясалу ассызыклана. Шагыйрь иҗатында гражданлык идеяләренең мәгърифәтчелек карашлары белән тыгыз гәүдәләнеше, яңа иҗтимагый шартларда Тукай мәгърифәтчелегенең яңа сыйфатларга баюы танылa. Һәм ул “революцион-демократик мәгърифәтчелек” баскычы дип бәяләнә. Һәм нәтиҗәдә әдәбият һәм сәнгатьнең иҗтимагый вазифасын мәгърифәткә өндәү белән генә чикләмичә, “җәмгыятьне үзгәртеп коруда революцион көрәш коралы булуын” да күрә

башлаган Тукай революцион-демократ шагыйрь буларак таныла. Шагыйрьнең мәгърифәтчелектән революцион- демократик позициягә басуы зур җиңү буларак шәрехләнә. Галим әдәби әсәрне уку, гыйлем һәм әхлакый мәсьәләләрне чагылдыру чарасы итеп караган мәгърифәтчеләрнең карашларын кире кагып, матур әдәбият иҗтимагый-сәяси карашларны белдерү мәйданы, берәмлек дип белдерә.

Г.Тукайның иҗтимагый позициясе, дөньяга карашларының үсеш-үзгәреш чорлары гыйльми күзалланганнан соң, И.Нуруллин шагыйрьнең әдәби-эстетик карашларын тикшерүгә күчә. Ул әдипнең эстетик карашларын формалаштыруда әдәби факторларның һәм сәнгать кануннарының да ролен таный.

Галим, Г.Тукай шигъриятенең халыкчанлыгын В.Белинский, Н.Чернышевский, А.М.Горькийларның әдәбиятның халыкчанлыгы турындагы эстетик карашларына таянып аңлата. Халыкчанлыкны әдәби әсәр эчтәлегенең төп категорияләреннән берсе төсендә санап, үз игътибарын Тукай шигырьләренең идея эчтәлегенә, аннан соң поэтикасына юнәлтә. Кызганычка каршы, хезмәттә Тукай иҗатының халыкчанлык хасияте социологик ноктадан тикшерелеп, шагыйрьнең иҗтимагый-сәяси карашларының формалашу баскычлары йогынтысында халыкчанлашуның чорлары аерып чыгарыла. Аның фикеренчә, шагыйрьнең мәгърифәтчелек чоры иҗатында “халыкчанлык әле чикләнгән булса”, “Тукай поэзиясенең чын-чыннан халыкчан булып китүе, бу халыкчанлыкның байый, тирәнәя һәм ныгый баруы” шагыйрьнең иҗтимагый-сәяси карашлары үсешенең икенче чорына карый.

Алга таба И.Нуруллин игътибарын Г.Тукайның әдәби эстетик карашларын калыплаштыруда рус классик әдәбиятының роленә юнәлтеп, Тукай гыйльмиятен яңа гыйльми күзаллаулар белән баета. Татар укучысының аң-фикерләү рәвешен, милли хосусиятләрен зәвык дәрәҗәләрен истә тотып, Тукайның рус әдәбиятыннан алынган әсәрләрне татар тормышына җайлаштыруы, адаптацияләве, шушы максатларда тәрҗемәнең, ияртүнең төрле формаларына – ирекле, сүзгә-сүз тәрҗемәләргә, нәзыйрә-пародияләргә

мөрәҗәгать итүе ассызыклана. Шагыйрьнең рус әдипләреннән чынбарлыкны дөрес итеп, реаль вакыйгаларда сәнгатьчә гәүдәләндерү осталыгына өйрәнеп, әдәбият-сәнгать турындагы теоретик карашларын тирәнәйтүе билгеләнә.

И.Нуруллин шагыйрьнең әдәби-тәнкыйди карашлары мәсьәләсен гыйльми күзаллауга алына. Ул XX гасыр башында әдәбият белеменең башка тармакларыннан аерылып, фән буларак мөстәкыйль үсеш юлына чыккан әдәби тәнкыйтьне формалаштыруда Г.Тукайның ролен югары бәяли. Г.Тукайның әдәби тәнкыйтьнең предметы, тәнкыйтьченең һөнәри осталыгы, әхлагы, әдәби әсәрне бәяләү кагыйдәләре хакындагы бәя-хөкемнәре аерып чыгарыла һәм алар, чор йогынтысында марксизм-ленинизм методологиясе яссылыгында шәрехләнәләр. Нәтиҗәдә Г.Тукайның әдәби тәнкыйтьнең теориясе турындагы карашлары идеялелек ноктасыннан өйрәнелә. Галим Г.Тукай тәнкыйтендә реализм һәм типиклык мәсьәләләрен В.Г.Белинский, К.Маркс, Ф.Энгельсның әдәбият хакындагы өйрәтмәләренә таянып шәрехли. И.Нуруллин Тукайның әдәби әсәрне бәяләү үлчәмнәреннән әсәрдә тормыш дөреслеген чагылдыру, чынбарлыкның әһәмиятле якларын дөрес тотып алып гомумиләштерү принципларын аерып чыгара.

И.Нуруллин Г.Тукайның әдәби-тәнкыйди карашларын 1910-еллар гыйльми-нәзар фикерендә әдәби әсәрне аңлау һәм шәрехләүдә күзәтелгән ике юнәлешнең, ике мәктәпнең – мәдәни-тарихи һәм психологик мәктәпләрнең көрәше контекстында карый. Бу мәсьәлә уңаеннан И.Нуруллин әдәби тәнкыйтьнең гомуми мәсьәләләрен яктырткан Г.Батталның “Тәнкыйть” (Шура. 1909. № 12. 360-362 б.) мәкаләсен анализлый һәм аның карашынча, Г.Баттал “идеялелек мәсьәләсенә кагылышлы бер генә сүз дә әйтми, аны әдәбиятның форма ягы гына кызыксындыра. Әдәби тәнкыйтьнең әһәмияте һәм бурычлары турындагы бу ике төрле караштан әдәби әсәрләрне анализлауның ике төрле принцибы килеп чыга.” (1, 73 б.). И.Нуруллин киң карашлы, әзерлекле тәнкыйтьче буларак, әдәби әсәрне анализлауның ике юнәлешен дөрес ассызыклый.

И.Нуруллинның «Тукай эстетикасы» хезмәте дә 1940-1950 елларда Тукай фәне үсешендәге сыйфатларның барысын да үз эченә алган. Ул Г.Тукай гыйльмиятен яңа күзәтүләр белән баета, аның яңа аспектларын күтәрә. Тукай фәненең хәзерге югарылыгыннан караганда, хезмәттә шагыйрь әдәби-эстетик карашларының үсеш закончалыкларын бәяләүдә, андагы аерым күренешләрне шәрехләүдә дөрес үк булмаган хөкемнәрнең урын алуы, берьяклы мавыгулар күзгә ташлана. Бу кимчелекләр, беренчедән, шул чорның идеологик басымы, икенчедән, әдәбият белеменең, шул исәптән, әдәби тәнкыйтьнең һәм әдәби-мәдәни мәсьәләләрнең гомуми торышы белән дә аңлатыла. Фәнни тикшеренүләрдә тәҗрибәнең азлыгы да үзен сиздерә. Шулай да хезмәт И.Нуруллинның киләчәктә гыйльми эзләнүләренең, Тукай турындагы күзаллауларының юнәлешен, кыйбласын билгели.

1960-1980 еллар – ХХ гасырда Тукай гыйльмияте үткән юлның иң бәрәкәтле һәм нәтиҗәле баскычы. Чыннан да, Тукай турындагы фән бу елларда үзенең җитлегү чорына килеп керә. Илдә барган иҗтимагый-сәяси үзгәрешләр Тукай иҗатын әдәби-эстетик күзаллауга, аның үсешенә йогынты ясый. Аннан соң Тукай турындагы фәннең эчке үсеш ихтыяҗы, үз кануннары һәм әдәби-теоретик фикернең үсеш дәрәҗәсе дә моңа җирлек әзерли.

И.Нуруллин Г.Тукай яшәгән чорның иҗтимагый – сәяси һәм әдәби – мәдәни фонын концептуаль тикшерми торып, шагыйрь иҗатының бөеклеген, шагыйрь феноменының серен аңлау һәм бәяләү мөмкин түгеллегенә төшенә. ХХ йөз башы әдәби хәрәкәте, аның күренекле вәкилләренең әдәби эшчәнлекләрен яктырткан И.Нуруллинның “ХХ йөз башы татар әдәбияты” [5] хезмәтендә шагыйрь Г.Тукай иҗатына махсус бүлек багышлана.

И.Нуруллин тарихилык һәм эстетик принципларга нигезләнеп, шагыйрь иҗатының эволюциясен, үсеш баскычларының хронологик чикләрен һәм төп хасиятләрен билгели. Ил күләмендәге тарихи вакыйгалар, иҗтимагый-сәяси вәзгыять, шәхси тормышындагы хәл-үзгәрешләр һәм шагыйрь иҗатында халыкчанлык белән реализм җәһәтеннән сыйфади яңарышлар күз уңында тотыла. Ә халыкчанлык һәм реалистик юнәлештәге борылышлар, алда

әйтелгәнчә, үз чиратында шагыйрь иҗтимагый-сәяси һәм эстетик карашларының революцион-демократик эчтәлек алуга нисбәтле шәрехләнә. Әдәби мәсьәләләргә бәя-хөкемнәрендә Г.Тукай шигъриятендәге әдәби күренешләрне шәрехләвендә эстетик анализ калкуланып китә.

Әдәби иҗатка Беренче рус инкыйлабының куәтле гөрелтеләре белән килеп кергән Г.Тукайның беренче чор иҗаты 1905 һәм 1906 елның беренче яртысы белән чикләнә. Уку, гыйлем, мәгърифәт һәм әхлак-тәрбия бу чорның төп темалары буларак аерып чыгарыла һәм ул "мәгърифәтчелек чоры" дип атала.

Галим 1906-1907 елларның беренче яртысы – ягъни икенче чорда Г.Тукайның, ил эчендәге иҗтимагый-сәяси вәзгыять, тарихи вакыйгалар йогынтысында конституцион ышанулардан арынып, революцион-демократик позициягә басуын билгели. Әлбәттә ул, шагыйрьнең әдәбият-сәнгатьнең иҗтимагый вазыйфасына карашлары үзгәрүгә бәйләп аңлатыла. Галим шагыйрьнең бу елларда иҗат ителгән әсәрләрендә, аеруча сатирасында чынбарлыкка, җәмгыятькә тәнкыйди мөнәсәбәтнең тирәнәюен "алар арасында тәнкыйди реализм таләпләренә бавап бирә торган шигырьләрнең барлыкка килүе" билгели. Г.Тукай сатирасының фаш итү объектларының киңәюе, көлүнең үткенәюе, жанрлар һәм алымнарының төрлеләнүе күрсәтелә.

Хәзерге вакытта Г.Тукай рухи мирасының Казан чоры дип каралган 1908-1913 еллар аралыгы И.Нуруллин тарафыннан ике баскычка: 1908-1910 һәм 1911-1913 елларга бүлеп тикшерелә. Бу елларда шигыйрь поэзиясе чын мәгънәсендә яңа сыйфатларга баеп, идея эчтәлеге һәм поэтикасы ягыннан да яңа биеклекләргә күтәрелә. Галимнең фәнни карашларында Тукай лирикасының эстетик һәм психологик аспектларына игътибары арта төшә.

Өченче чорда лирик геройның табигате үзгәрү, лирик "мин"нең драматик һәм фаҗигале күңел кичерешләрен тасвирлау, психологизм тирәнәю, алда ассызыкланган сәбәпләрдән тыш, Тукай шигъриятенең иҗат ысуллары ягыннан төрлеләнү белән дә бәйләп шәрехләнә. Аурупа тибындагы башлангычның көчәеп китеп, шагыйрьнең реакция еллары лирикасында романтизм белән

янәшә тәнкыйди реализмның янәшә яшәве хакында яңа гомумиләштерү ясала. И.Нуруллин Г.Тукай иҗатында тәнкыйди реализмның ныгуында микъдар һәм сыйфат ягыннан яңа баскычка күтәрелгән сатираның ролен күрсәтә. Галим шагыйрь поэзиясенең иҗат алымнары, жанр формалары ягыннан баюын да Г.Тукайның сатирик юнәлештә нәтиҗәле эшләве белән бәйләп карый. Мондый эчтәлектәге әсәрләрдә көлү һәм фаш итү объектларының диапазоны киңәю ассызыклана.

Г.Тукайның 1911-1913 еллар әдәби иҗатын дүртенче чор итеп аерып чыгаруда автор Россиядәге ревоюцион хәрәкәтнең яңа күтәрелешен һәм әдәби-эстетик карашларын нигез итеп ала. Шагыйрьнең соңгы чор иҗатында реолюцион – демократизм һәм тәнкыйди реализмның тулысынча җиңеп чыгуны раслый. Шагыйрьнең  бу елларда иҗат ителгән бер төркем шигырьләрендә, мәсәлән, “Яшьләр” (1910), “Татар яшьләре” (1912), “Аң” (1912) “Даһигә” (1913) әсәрләрендә киләчәккә ышаныч, иҗтимагый барыш, тарих хәрәкәтендәге уңай үзгәрешләргә өмет, ягъни тарихи оптимизмның көчәюе ассызыклана. И.Нуруллин, фәнни эзләнүләренә таянып, Г.Тукайның XX йөз башы татар әдәбиятында бер әдәби мәктәп тудырып, татар поэзиясенең яңарышын һәм үсеш юнәлешен билгеләве турында нәтиҗә ясый.

Галим бу чорда Г.Тукайның шигъри дөньясын өйрәнүне дәвам итеп «Тукай иҗаты: Беренче рус революциясе чоры» (1964) (8) хезмәтен нәшер итә. Р.Якупов белән берлектә Тукай биографиясен яңа фактлар, яңа тормыш детальләре тулыландырган, бәхәсле урыннарга ачыклык керткән «Тукай турында хатирәләр» «Тукай турында истәлекләр» (1986) (9) китапларын чыгара.

Шул ук вакытта И.Нуруллин бу вакытта матбугат битләрендә Тукай иҗатын өйрәнүнең актуаль, җитди мәсьәләләрен яктырткан проблемалы, бәхәсле мәкаләләр белән чыгыш ясый.   Шундый әдәби бәхәсләрнең берсен ул 1966 нчы елда «Казан утлары» битләрендә «Шагыйрьне өйрәнү юлында» (10) дигән мәкаләсе белән башлап җибәрә. Анда Тукай фәненең торышы, шагыйрь иҗатының идея юнәлеше, кайбер галимнәрнең шагыйрь карашларын

билгеләүдә берьяклы мавыгулары, Тукайның дингә мөнәсәбәте, аның сәнгатьчә фикерләү үзенчәлекләрен яктырту һ.б. мәсьәләләр күтәрелә. Бу бәхәстә М.Гайнуллин (11), К.Фасеев (12), М.Абдрахманов (12), Р.Нәфыйгов (13), Г.Халитләр (14) катнаша. Мәкаләләр циклына, әдәби бәхәскә Г.Халитнең «Бер бәхәс уңае белән» дигән язмасы йомгак ясый. 1960 нчы еллар әдәби-гыйльми фикеренең Тукай шигъриятендә моңа кадәр зур бәхәсләргә сәбәп булган дини мотивларны тануы, берьяктан, зур җиңү була. Дөрес, И.Нуруллин да, Г.Халит тә Тукай шигъриятендә дини мотивларның яңгырашын шагыйрьнең ялгышулары, «дөньяга карашында» тарихи сәбәпләр белән аңлатыла торган каршылыклар» белән бәйләп карыйлар.

И.Нуруллинның татар әдәбиятында тәнкыйди реализмның барлыкка килүен һәм үсешен өйрәнүгә багышланган докторлык диссертациясе нигезендә «Путь к зрелости» (15) исемле монографиясе дөнья күрә. “XX йөз башы әдәбиятын иҗат методы проблемасы аркылы өйрәнеп, фәндә яңа сүз әйтеп, әдәби-эстетик фикерне яңа баскычка күтәргән» (16, 239 б.) хезмәттә галим татар әдәбиятында реалистик юнәлеш агымнарының көчешен, алардагы төп сыйфатларның үзгәрешен башка язучылар белән беррәттән Г.Тукай иҗатын үзәккә куеп шәрехли һәм ул милли әдәбиятта яңа реалистик агымның нигез ташларын салучы буларак бәяләнә.

XX гасыр башында нәшер ителгән газета-журналлардагы шагыйрь һәм аның даирәсе белән бәйле булган материаллар, хатирә - истәлекләр, архив чыганаклары һәм төрле шәкелдәге язмалар белән танышу, И.Нуруллинга, беренчедән, монографик хезмәтләрендә дәлилле, фәнни хөкем йөртергә мөмкинлек бирсә, икенчедән, аның күңелендә пыскып яткан әдәби иҗат дәртенә ялкын өсти. 1960 елларда И.Нуруллин документаль – биографик жанрдагы әдәби әсәрләр иҗат итүгә керешә: “Тукай Петербургта” (1965) (17) һәм “Тукай турында хикәяләр” (1971) (18), рус телендәге “Поэт из деревни Кырлай: рассказы о Габдулле Тукае” (1967) (19) һ.б. әсәрләрендә шагыйрьнең шәхси тормышыннан алынып, авторның иҗади уйланмасы белән баетылган

сурәт-картиналарда Тукайның җанлы һәм якты образы тудырыла, аның шәхси кичерешләре, бәя-хөкемнәре чагыла.

Галимнең бу төр эшчәнлегенең иң югары ноктасы булып әдәби-документаль жанрда язылган “Габдулла Тукай” (1979) (20) исемле китабы тора. Гәрчә әсәрнең язылу вакыты 1974-1976 елларны эченә алса да, ул әдип-галимнең дистә елларга сузылган фидакарь хезмәтенең нәтиҗәсе булып тора. Үзгәртеп кору елларында китап яңа исемнәр, сәхифәләр белән баетыла, һәм аның төзәтелгән һәм тулыландырылган икенче басмасы, автор үзе вафат булгач, 2000 елда «Моңлы саз чыңнары» (21) исемендә басылып чыга һәм аның жанры документаль роман буларак билгеләнгән.

Дөнья әдәбиятында гына түгел, милли әдәбият тарихында бай тарихы булган бу жанрдагы әдәби әсәрләр соңгы еллар әдәбият белемендә зур кызыксыну уятты (22). И.Нуруллин әсәрдә Г.Тукай иҗатын XX гасыр башындагы тарихи вакыйгалар һәм иҗтимагый-милли тормыш күренешләре белән тыгыз бәйләнештә яктырта һәм үзенең әдәби-эстетик, фәлсәфи бәясен белдереп бара. Галим-биограф тарафыннан шагыйрь тормышындагы вакыйгалар, әдәби-мәдәни фактларның аның иҗатына тәэсире, йогынтысы анализлап барыла. Безнең карашыбызча, “Моңлы саз чыңнары” әсәре язучының әдәби-фәнни биографик жанрда иҗат ителгән, ул үзенең идея эчтәлеге белән шушы форма таләпләренә туры килә. Автор романда документаль һәм әдәби башлангычларны шагыйрь иҗаты хакындагы бәя-хөкемнәре һәм фәнни карашлары белән үреп, синтезлап бара. Алар арасында гармоник ярашу нәтиҗәсендә И.Нуруллин Тукай хакында эстетик һәм тарихи яктан кыйммәтле әсәр тудыруга ирешкән.

Документаль романда И.Нуруллинның шагыйрь иҗатын бәяләгән катламда Тукайның әдәби-эстетик карашларын тикшерүдә тоткан юлын, мәсләген мәдәни-тарихи юнәлеш рамкасы белән чикләп кую дөрес булмас иде. Мәдәни-тарихи мәктәпнең формалашуына нигез булган биографик метод ысулы Г.Тукайның аерым иҗат чорларын өйрәнүдә И.Нуруллин тарафыннан иркен файдаланыла.

Шагыйрьнең аерым чор “күңел җимешләрен” анализлаганда, психологик мәктәпнең кагыйдәсенә дә мөрәҗәгать итә һәм бер төркем әсәрләрен, бүгенге татар әдәбият белемендә фәнни әйләнешкә кертелгән модернистик агымның терминын файдаланмаса да, экзистенциализм фәлсәфәсе яссылыгында, яшәү, яшәеш фәлсәфәсе ноктасыннан шәрехли. Шагыйрьнең эчке кичерешләре, җаны, йөрәк тавышы ишетелгән “Катиле нәфескә” (1910), “Өзелгән өмид” (1910), “Газаптан соң” (1910), “Өмидсезлек” (1910) шигырьләре шушы дулкында аңлатыла.

Шулай итеп, И.Нуруллин Г.Тукай турындагы гыйльми күзаллауларның фән буларак формалашуында үзәк урынны алып тора. Галим эзләнүләре, иң беренче нәүбәттә, шагыйрь иҗатын, аның үсеш-үзгәреш баскычларын, асыл хасиятләреннән халыкчанлык һәм реализм мәсьәләләрен тикшерү белән бәйләнгән. И.Нуруллин Тукай гыйльмиятенең үзәген билгеләгән бу проблемаларны шагыйрьнең әдәби-эстетик һәм дөньяга карашлары белән тыгыз бәйләнештә шәрехли. Аннан соң, И.Нуруллин татар халык шагыйре Г.Тукай шәхесен, аның кыска, әмма бай тормышын, хисси – эмоциональ, образлы чагылдыру юнәлешендә дә милли әдәбият тарихында үзгә сукмагын булдыра. Ул әдәби әсәрләрендә һәм “Моңлы саз чыңнары” китабында галим, биограф һәм әдип буларак чыгыш ясый. Шуның белән Тукай әдәби осталыгының, үлемсез шигъриятенең серләренә укучыны төшендерә.

Әдәбият:

1. Нуруллин И.З. Тукай эстетикасы турында мәкаләләр / И.З.Нуруллин. – Казан: Таткнигоиздат, 1956. – 136 б.
2. Заһидуллина Д.Ф. Әдәбият кануннары һәм заман (Татар әдәбият нәзариятенең барлыкка килүе һәм үсеш баскычлары). / Д.Ф.Заһидуллина. – Казан: Татар.кит.нәшр., 2000. – 271 б.
3. Тукай Г.Сайланма әсәрләр. Ике томда. 2 том / Мәкаләләр, истәлекләр, хатлар / Тукай Г. – Казан: Татар.кит.нәшр., 2006. - 383 б.

4. Сүнчәләй С. Мияубикә / С.Сүнчәләй // Әсәрләр һәм хатлар. – Казан: Татар.кит.нәшр., 2005. – 230-231 б.
5. Нуруллин И. XX йөз башы татар әдәбияты: Урта мәктәп укытучылары, студентлар һәм югары класс укучылары өчен дәреслек-кулланма / И.Нуруллин. – Казан: Татар.кит.нәшр., 1982. – 288 б.
6. Ганиева Р.К. Шагыйрьнең рухи дөньясы: «Габдулла Тукай» энциклопедик сүзлек-белешмәсенә әзерләнгән материаллардан) / Р.К.Ганиева. – Казан: ТаРИХ, 2002. – 112 б.
7. Халит Г. Тукай үткән юл ( Габдулла Тукайның тормышы һәм иҗаты турында очерк) / Г.Халит. – Казан: Татар.кит.нәшр., 1962. – 230 б.
8. Нуруллин И.З. Тукай иҗаты: Беренче рус революциясе чоры / И.З.Нуруллин. – Казан: Казан университеты нәшр., 1964. – 111 б.
9. Тукай турында хатирәләр / Төз. И.Нуруллин, Р.Якупов. – Казан: Тат.кит.нәшр., 1976. – 190 б. Тукай турында истәлекләр / Төз. И.Нуруллин. Р.Якупов. – Казан: Тат.кит.нәшр., 1986. – 256 б.
10. Нуруллин И.З. Шагыйрьне өйрәнү юлында / И.З.Нуруллин // Казан утлары. – 1966. - №3. – 120-127 б.
11. Гайнуллин М. Дөреслекне төгәл яктыртыйк / М.Гайнуллин // Казан утлары. – 1966. - №7. – 124-127 б.
12. Абдрахманов М., Фасеев К. Гүзәл хәзинәне яклап / М.Абдрахманов, К.Фасеев // Социалистик Татарстан. – 1966. – 24 май.
13. Нәфыйгов Р.И. Габдулла Тукай биографиясен өйрәнүнең кайбер мәсьәләләре / Р.И.Нәфыйгов // Казан утлары. – 1966. - №8. – 119-128 б.
14. Халит Г. Бәхәссез һәм бәхәсле хакыйкатьләр / Г.Халит // Совет әдәбияты. – 1966. - №4. – 75-86 б.
15. Нуруллин И.З. Путь к зрелости: о зарождении и развитии критического реализма в татарской литературе / И.З.Нуруллин. – Казань: Татар.кн. изд-во, 1971. – 348 с.

16. Миңнегулов Х.Й. Унҗган гасыр каһарманнарының берсе / Х.Й.Миңнегулов. Гасырлар өнен тыңлап. – Казан: Мәгариф, 2003. – 237-241 б.
17. Нуруллин И. Тукай Петербургта / И.Нуруллин. – Казан: Тат.кит.нәшр., 1965. – 92 б.
18. Нуруллин И. Тукай турында хикәяләр / И.Нуруллин. – Казан: Таткнигоиздат., 1956. – 135 б.
19. Нуруллин И.З. Поэт из деревни Кырлай: рассказы о Габдулле Тукае / И.З.Нуруллин. – М.: Детская литература, 1967. – 92 с.
20. Нуруллин И. Габдулла Тукай / И.Нуруллин. – Казан: Тат. кит. нәшр., 1979. – 304 б.
21. Нуруллин И. Моңлы саз чыңнары: Документаль роман. Төзәтелгән һәм тулыландырылган икенче басма / И.Нуруллин. - Казан: Татар. кит. нәшр., 2000. – 272 б.
22. Башкуров Р. Тукай һәм рус әдәбияты: шагыйрьнең тәрҗемәләре хакында / Р.Башкуров. – Казан: Таткнигоиздат, 1968. – 122 б. Холиков А.А. Биография писателя как жанр. Учебное пособие / А.А. Холиков. – М.: Книжный дом “ЛИБРОКОМ”, 2000. – 96 с.;
23. Әдәбият белеме. Терминнар һәм төшенчәләр сүзлеге. – Казан: Мәгариф, 2007. – 231 б.